

Боек татар шагыйре, якташыбыз Һа-ди Такташ аналар турында болай дип язган: «...Ана – Боек исем, нәрсә житә ана булуга; хатыннарнын ботен матурлыгы, ботен кvрке ана булуда... »
Һәрбер хатын-кызга бәхетле әни, соекле хатын, яраткан әбекәй булырга язсын! Нарасыен кvкрәгенә кысып, газиз баласынын керфек кагышына кадәр соенеп караган анадан да кvркәм зат юктыр жир йозендә.
Кvптән тvгел, Ромоданово районын-да яшәvче ирле-хатынлы Шарибжановлар, ана капиталы ярдәмендә vзләренен торак шартларын яхшырт-каннар, vз йортларын булдырганнар.       Әйтеп vтим, Альбина белән Александр Шәрибжановлар гаиләләрендә оч бала тәрбияләп vстерәләр. Гаиләдә олылар «Ромодановосахар» жәмгыятчелегендә хезмәт итәләр. Үз йортын тозекләндерvгә акча кирәк булган вакытта, ярдәм сорап, vзләре эшләгән предприятие жи-тәкчесе А.И.Атласовка морәжәгать иткәннәр. Ул аларга барлык башлангыч эшләрендә ярдәм иткән һәм бу гаилә житәкчеләренә рәхмәтле. Ә ин башта хокvмәтебезгә рәхмәтләрен житкерәләр.
Альбина ханым ана булу рәхәтме дигән сораугa болай дип жавап бирде:
- Әни булу – зур бәхет, бvләк ул. Гаиләнен яме шунда. Тормышымда минем топ ярдәмчеләрем - ирем һәм улларым. Алар белән мина хатын һәм әни булу жинел. Ирем таләпчән булгалый, әмма еш кына компромисска бара. Ул балалары алдында зур абруй били. Һәр баласын бик ярата, ә алар, vз чиратларында, ана шул ук хисләр белән жавап бирәләр. Без тату яшибез. Бер-беребезгә ярдәм итәргә һәрвакыт әзер. Кvп балалы гаиләнен тормышы, чыннан да, авыр, әмма авырлыклар арасында якты мизгелләр таба белергә кирәк. Ин моһиме, барысын да дорес итеп оештырырга һәм vзенә беркайчан да тынып тормаска һәм йомшармаска кирәк дип саныйм. Ял итәргә, коч туп-ларга да вакыт килер әле, - диде язма героебыз әнгәмә вакытында.
Балалары турында да белләсегез киләдер. Шарибжановларнын олкән уллары Азат, Ичалки районындагы Кемля аграр коллиятенен Ромодан филиалынын 4 курсында укый; ул - булачак механик. Волейбол белән мавыга һәм Ромоданово балалар-яшvсмерләр спорт мәктәбе секциясенә йори. Уртанчы балалары - уллары Азамат, шул ук аграр коллиятнен 2 нче курс студенты; газ белән эретеп ябыштыручы һонәрен vзләштерә. Шулай ук футбол секциясенә йори.
- Балаларнын спорт белән дус булулары - гаилә башлыгынын казанышы; бу мине бик тә шатландыра. Сойләшvләр очен уртак темалары бар, алар даими рәвештә нәрсә дә булса турында фикер алышалар,- дип уртаклаша хужабикә Альбина гаиләсе турында.
Ботен гаилә очен оч яшьлек Алина – аларнын шатлыгы. Ул балалар бакчасына йори, анда активлык һәм кызыксынучанлык кvрсәтә. Әниләре сvзләренә караганда,

Алиналары бик тә рәсем ясарга ярата. Әти-әниләре яшь рәссамнын бу теләген тыеп тормый; алар кызларына буяулар, матур тосле фломастерлар, карандашлар белән рәсем ясарга момкинлек бирә.
Кvпләр гаиләдә балалар кvбрәк булган саен, ата-анада һәр балага вакыт азрак кала, дип саный. Әмма Альбина ханым һәр балага шәхси вакыт бирергә, аларнын унышлары, планнары белән кызыксынырга тырыша. Язма героебыз раслаганча, кичке аш әзерләгәндә дә, әйтик, барлык ризыклар арасында анын ин яраткан ризыгы - мантый пешергәндә дә аралашырга була, ди.
Кыскасы, әни булу - бvләк, бу бәхеткә һәрбер хатын-кыз лаек булсын иде.

**Наилә НАСЫРОВА**